

Мордовиянен теләсә кайсы районында татар милләте вәкилләре яшәве билгеле. Шул исәптән Чамзинка районында да. Күптән түгел бу районны Руслан Альфред улы Батеряков житәкләде. Анын беренче адымнары - эшләнгән эшләре һәм чишәсе мәсьәләләре турында.

Мордовия Главасы Артем Здунов Чамзинка районынын социаль-икътисадый үсеше мәсьәләләре буенча кинәшмә үткәргән иде.Кинәшмәдә Чамзинка районы башлыгы Руслан Батеряков территория үсешенен күрсәткечләрен үтәү барышы турында хәбәр итте.

«АПК һәм сәнәгать предприятиеләре унай динамика белән эшли. Аерым алганда, агымдагы елнын ярты елында тавык йомыркасын житештерү 108 млн. житте - узган ел белән чагыштырганда 120%. 2022 елнын 1 кварталында АПК предприятиеләрендә уртача айлык хезмәт хакы, узган елнын шушы чорына караганда, 17% ка артты һәм 41 мен сумнан артып китте.2022 елда 6 инвестицион проект-ны гамәлгә ашыру планлаштырылды, алар нәтижәсендә 2,2 млрд. сум үзләштерелде һәм 194 остәмә эш урыннары булдырылачак.
Ярты елда үз керемнәрен керү күләме 140% ка үтәлде. Милли проектларны тормышка ашыру кысаларында социаль объектлар тозү һәм ремонтлау актив бара», - дип сойләгән иде Чамзинка районы житәкчесе Р.А.Батеряков.



